# Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге

Төзүчесе:
*Хәлил Сәлимов*

Казан
«Яңалиф» нәшрият йорты
2004

УДК 811.512.145
ББК 81.2 Тат–4
С 94

Төзүчесе:
Сәлимов Хәлил Хәлимович
филология фәннәре докторы,
Алабуга дәүләт педагогия университеты профессоры

Рецензентлары:
*М.З. Зәкиев,* филология фәннәре докторы, академик
*Л.Ш. Арсланов,* филология фәннәре докторы, Алабуга дәүләт педагогия университеты профессоры

Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. Казан: «Яңалиф» нәшрияты. – 2004. – 192 бит.

Бу сүзлек гомум кабул ителгән һәм татар теленең Академик грамматикасында тасвирланган орфография, орфоэпия кагыйдәләре нигезендә төзелде. Сүзлектә әйтелеш-язылыш арасында беркадәр аерма булган, авыррак язылышлы һәм әйтелешле ун меңнән артык сүз теркәлде. Сүзләрнең язылышы кириллицада һәм 1999 нчы елда кабул ителгән латин графикасында бирелә, шуннан соң гадиләштерелгән гамәли транскрипциядә сүзнең әйтелеше (авазларның әйтелеше, сүз басымы һ.б.) күрсәтелә. Сүзлек мәктәп укучылары, студентлар, татар теле укытучылары, радио-телевидение хезмәткәрләре һәм, гомумән, киң катлау укучылар өчен гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

ISBN 5-94352-012-0 © “Яңалиф” нәшрияты, 2004

## *Кереш*

Татар әдәби теленең, башка телләрнеке кебек үк, үзенең нормалары бар. Алар телнең барлык якларын да – сүзлек составын, грамматик төзелешен, аваз системасын үз эченә алалар. Кайбер нормалар – язма телгә, икенчеләре сөйләм теленә карыйлар. Мәсәлән, язма сөйләмгә кагылышлы нормалар (дөрес язу кагыйдәләре) орфография дип атала. Сөйләм теле нормаларының җыелмасын (дөрес әйтелеш кагыйдәләрен) орфоэпия диләр. Орфоэпик күренешләр, еш кына, язуда чагылыш тапмыйлар.

Бу хезмәтнең актуальлеге иң элек татар теленең орфоэпик нормативларын өйрәнүче фәннең җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы белән бәйле. Татар теленең орфографик сүзлекләре берничә мәртәбә басылып чыкты инде. Ә менә, орфоэпик сүзлекләрнең булуы барлык телләр өчен дә гаять дәрәҗәдә кирәкле булуга карамастан, татар тел гыйлемендә бу мәсьәләгә бик озак вакытлар тиешле игътибар бирелмәде: татар теленең беренче орфоэпик сүзлеге бары 1995 нче елда гына төзелеп бетте һәм басылып чыкты. Әлеге сүзлекнең мөһимлеге, икенчедән, туган телне укыту методикасының проблемалары, аерым алганда туган телнең орфоэпик нормаларына өйрәтү мәсьәләләре белән дә бәйле. Еш кына туган телне өйрәтү процессында татар теле укытучылары үз алларына иң элек бер максатны куялар – балаларны дөрес язарга өйрәтергә. Ә балаларны дөрес һәм матур сөйләшергә өйрәтү, орфоэпик нормаларны үзләштерү мәсьәләләре игътибардан читтә кала. Ә бит моның өчен татар теле укытучылары үзләре татар теленең просодик-орфоэпик үзенчәлекләрен бөтен нечкәлекләре белән белергә тиешләр. Орфоэпик нормаларны белү татар телен бу телне бөтенләй белмәүчеләргә укытучы мөгаллимнәр өчен аерата әһәмиятле. Өченчедән, бу сүзлектәге мәгълүматлар сәнгатьле уку, сәхнә теле белән бәйле кешеләргә, бигрәк тә радио-телевидение хезмәткәрләре, беренче чиратта дикторлар һәм журналистлар өчен дә мөһим. Югыйсә еш кына татар

радио-телевидениесе тамашачылары кайбер яшь журналистларның, диктор һәм артистларның авазларны, сүзләрне ялгыш әйтүләре, татарча дөрес сөйләшә белмәүләре турында нигезле претензияләр белдерәләр. Уртак орфоэпик-просодик нормаларны үзләштерү – төрле регионнарда яшәүче татарларның сөйләмен бер-беренә якынрак һәм аңлаешлырак итүче фактор.

Шулай итеп, татар теленең орфоэпик нормаларын эшкәртү, аларны туплап бирү төрле өлкәләр һәм сфералар өчен мөһим һәм актуаль проблема булып тора: ул фәнни-гамәли тел гыйлеменә дә, мәгарифкә, мәдәнияткә һәм хәтта тел вәкилләренең иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә дә кагыла.

## *1. Сүзлекнең бурычы һәм максатлары*

Бу сүзлек орфографик-орфоэпик сүзлек булып тора, ягъни аның максаты – язма телгә һәм сөйләм теленә хас булган нормаларны чагылдыру. Сүзлектә төрле грамматик формаларда әйтелешнең үзгәргән очраклары да күрсәтелә. Бирелә сүзләрнең мәгънәләренә аңлатма бирелми. Бары сүзлекнең максатыннан чыгып кына, кайбер сүзләргә семантик аңлатмалар бирелә. Татар теленең теләсә нинди сүзлеге кебек үк, бу сүзлек тә гамәлдәге орфографик кагыйдәләргә нигезләнә, шуңа күрә сүзлеккә кертелгән лексиканы орфографик белешмә буларак та файдаланырга мөмкин. Сүзлек татар әдәби телендә булган барлык сүзләрнең язылыш-әйтелешен күрсәтүне дә максат итеп куймый, беренче чиратта әйтелеш һәм язылыш арасында аермалар булган сүзләр алынды.

Мәгълүм булганча, 1999 нчы елның 15 нче сентябрендә «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» Татарстан Республикасы Законы дөнья күрде, һәм бу Законның әле гамәлдән чыгарылганы юк. Шуңа күрә бу сүзлектә сүзнең кириллицадагы язылышыннан соң аның яңа кабул ителгән латин графикасындагы язылышы да бирелә. Бирелә латин графикасындагы язылышның әйтелешкә никадәр якын булуы да ачык күренә.

## *Сүзлекнең төзелеше*

1. Сүзлектә барлык сүзләр алфавит тәртибендә юл хәрефе белән бирелә, ялгызлык исемнәренең әйтелешендә үзенчәлекләр булганда, алар баш хәреф белән биреләләр.

2. Сүзләрнең әйтелешен хәзерге татар телендә кулланылучы гадиләштерелгән (гамәли) транскрипция тамгалары белән бирү кулайрак күрелде. Бу исә беренче чиратта кириллицага нигезләнгән хәзерге татар язуында татар авазларын белдерүче бик күп хәрефләрнең җитмәве һәм шуңа бәйле әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма булу белән бәйләнгән. Татар гамәли транскрипциясенең тамгалары чагыштырмача бик гади булганга, материалның болай бирелүе укучыда кыенлыклар тудырмас дип уйларга мөмкинлек бирә.

Транскрипция тамгалары турында түбәндәгеләрне әйтергә була. Транскрипциядә барлык аваз үзгәрешләре дә чагылыш таба, һәр хәреф һәрвакыт бер генә авазга билге булып йөри, авазның өстәмә билгеләре (озынлык-кыскалык, нечкәлек, басым һ.б.) махсус өстәмә (диакритик) билгеләр белән белдерелә: [¯] – авазның озынлыгын, [˘] – авазның кыскалыгын, [’] – үзеннән алдагы тартык авазның нечкә (йомшак) әйтелүен күрсәтә. Транскрипцияләнә торган текст (сүз, җөмлә һ.б.) квадрат җәяләр [] эченә алына; дифтонглар таркатып языла ([йа], [йу], [йы], [йе] һ.б.); һәр сүзнең басымы куела.

Татар теленең гамәли транскрипциясе татар әлифбасына нигезләнгән, бары түбәндәге өстәмә тамгалар кертелгән: [қ] – кече телдә әйтелә торган «къ» тартыгы; [ғ] – кече телдә әйтелә торган «гъ» тартыгы; [w] – өрелмәле ирен-ирен сонанты; [’] – бугазда әйтелә торган йомык тартык; [ō], [ē], [ы̄] – рус алынмаларында очрый торган озын әйтелешле *о, е, ы* сузыклары; [ы̆], [ĕ], [ŏ], [ө̆] – басымсыз позициядәге редукцияләнгән *ы, е, о, ө* сузыклары.

Фонетикада гомуми танылганча, сүз эчендә бер үк тартык кабатланып янәшә килгәндә, ике аваз әйтелми, ә бер озын тартык кына әйтелә. Шуңа күрә андый очракларда тартык авазның

өстенә озынлык билгесе генә куелды: аккош aqqoş [аᵒк̄ош́], баллау ballaw [баᵒл̄а́ᵒw] һ.б.

Төрле комбинатор һәм позицион сәбәпләр аркасында берәр аваз икенче аваз төсмере белән әйтелсә, өстәмә тембр бирүче аваз төп авазны белдерүче тамганың уң ягында, өстәрәк шул тамга белән күрсәтелде: [баᵒлды́зʿ] һ.б. Фонема дәрәҗәсендәге аваз булмаган, ләкин беркадәр ишетелеп китә торган аваз элементлары да (абсолют сүз азагындагы [у], [ү], [и] авазлары ахырындагы [w], [й] авазлары, [и] авазы белән башка сузыклар арасында интерфикс элементы буларак кына әйтелә торган [й] авазы һ.б.) нәкъ шундый ук юл белән күрсәтелделәр: [бәби́ʸ], [даᵒру́ʷ], [диʸү́ʷ] һ.б.

Мәгълүм булганча, татар телендә кайбер сүзләр бөтенләй басым кабул итмиләр, бары басымлы сүзләргә ияреп киләләр һәм басымлы сүз белән бергә бер фонетик сүз барлыкка китерәләр. Андый очракларда сүзләр транскрипциядә кушылып язылалар: шулай дип [шула́йдип], әллә бар [әл̄әба́ᵒр] һ.б.

3. Билгеле булганча, әдәби әйтелеш үзе төп ике төргә бүленә: тулы стиль һәм сөйләшү стиле. Тулы стиль – сөйләмнең бик анык булуы таләп ителгән очракларда (дикторлар, лекторлар, укытучылар сөйләмендә), ә сөйләшү стиле кешеләрнең үзара сөйләшеп аралашуларында кулланыла.

Тулы стильдә сүзләрнең барлык иҗекләре дә диярлек ачык әйтелә, ә сөйләшү стилендә, кайбер иҗекләрнең кыскаруы, төшеп калуы күзәтелә. Кайбер позицион һәм комбинатор аваз үзгәрешләре дә сөйләм стилендә тулырак чагыла.

Сүзлектә кайбер очракларда бу әйтелеш вариантларының икесе дә бирелә, башта – тулы стиль варианты, аннан сөйләшү стилендәгесе языла.

аңламастан aŋlamastan [аᵒңла́мастан], *яки* [аᵒңна́мастан]

бөгелү bөgelü [бө̆гә̆лү́ʷ], *яки* [бө̆глү́ʷ]

4. Татар телендә сүз басымының чагыштырмача көчсезрәк булуы кайбер очракларда вариатив басым барлыкка китергән, ягъни басым бер үк сүздә ике урында килә ала. Сүзлектә аларның

икесе дә күрсәтелә. Ләкин киләчәктә аларның берсен генә орфоэпик норма итеп калдырырга кирәк дип уйлыйбыз.

бүредәй büredəy [бүре́дәй], *яки* [бүрĕдә́й]

сабантуй sabantuy [са°ба°нтӳй] *яки* [са°ба́°нтуй]

5. Кубиҗекле фонетик сүзләрдә еш кына көчсезләнгән өстәмә басым була. Ул [`] тамгасы белән күрсәтелә.

абагасыманнар abağasımannar [а°баға́сы̆ма°н̄а̀р]

6. Омонимнар рим цифрлары белән күрсәтелә, алар я аңлатыла, кыскартылма тамгалар белән аларның кайсы сүз төркеменә каравы җәяләрдә курсив белән билгеләнә.

адаш I *(исем)* adaş [а°да́ш]

адаш II *(фиг.)* adaş [а́°даш]

арка I *(архит.)* arka [а́ркы: а́ркы̆да, а́ркы̆ны] *һ.б.*

арка II *(анат.)* arqa [а°рқа́: а°рқада́, а°рқаны́] *һ.б.*

Кайбер очракларда омонимнарның мәгънәсен аңлату өчен русча тәрҗемәләре бирелде.

ачу I *(фиг.)* (открыть) ...

ачу II *(фиг.)* (киснуть) ...

7. Сүзлектә исемнәр баш килеш формасында бирелә. Төрләнгән вакытта басым һәм аваз үзгәрешләре килеп чыга торган очракларда, төрләнеш формалары, кушымчалары да күрсәтелә.

абзый abzıy [а°бзы́й: –ла́р, –ға́] *һ.б.*

8. Рус теленнән һәм рус теле аша кергән алынмаларның әйтелеше татар теленә нигездә рус орфоэпиясе нормалары буенча кабул ителгәнгә һәм, рус теленнән кергән алынмаларның гаять күп булуын истә тотып, андый алынмаларның зур күпчелеге сүзлеккә кертелмәде, сүзлектә бары әйтелешләре аеруча авыр булган, кушымчалар ялгаганда, әйтелеш ягыннан катлаулылык тудыра торган һәм татар сүзләре белән омографлар барлыкка китерә торган очраклар гына теркәлде.

абитуриент abiturient [абитуриʸē´нт]

абонемент abonement [абанēмē´нт]

диван I *(мебель)* divan [дива́н]

диван II *(җыентык)* diwan [диwа́°н]

9. Бер үк исемнең төрлечә әйтелгән очраклары да очрый. Әдәби телдә, язучылар телендә, сөйләм телендә аларның һәрберсе бер үк дәрәҗәдә диярлек кулланыла. Алар да сүзлектә үз урыннарын алдылар. Гадәттә алар бер статьяда бирелде, иң актив, норматив дип саналганнары беренче булып китерелде.

газета gazeta [газе́та], *яки* [газе́т]

котлет kotlet [катле̄т] *яки* [кәтли́т]

10. Фигыльләрне кайбер сүзлекләрдә – инфинитив формасында, икенчеләрендә исем фигыль формасында бирәләр. Исем фигыль формасының әйтелеше үзенчәлеклерәк булганга күрә, биредә дә шушы форма алына. Заман, зат-сан, барлык-юклык белән төрләнгәндә, төрле әйтелеш очраклары булганда, гадәттә, алар да күрсәтеп барыла.

абайлау abaylaw [а°ба°йла́°w: а́°ба°йла, а°ба°йлы́йм, а°ба°йлы́йбы̆зс, а°ба°йлады́, а°ба°йла́р, а°ба°йлайача́к, а°ба°йла́ма, а°ба°йла́мы̆йм, а°ба°йла́мы̆йбызс] *h. б.*

11. Сыйфатлар үзләренең төп формаларында бирeләләр. Чагыштыру дәрәҗәсе ясалганда, аваз үзгәрешләре күзәтелсә, ул формалар аерым күрсәтелә.

ак, аграк aq, ağraq [а°қ, а°ғра́қ] h.б.

Сыйфатларның хосусый кисәкчәләр белән ясалган артыклык дәрәҗәләре сүзлектә аерым бирелә. Гадәттә бу кисәкчәләр, басымны үзләренә алып, төп сыйфатны проклитика итеп ияртеп кенә килгәнгә, транскрипциядә алар кушылып язылалар.

ап-ачык ap-açıq [а́°бачы̆қ]

дөп-дөрес døp-døres [дө̆пдө̆рәс]

12. Саннарның барлык төркемчәләре дә диярлек аерым бирeләләр. Микъдар саннарында басым ахыргы иҗектә була, ләкин санаганда, шул ук саннарның басымы үзгәрә, беренче иҗеккә күчә. Шуңа мондый очраклар аерым күрсәтеләләр.

ике ike [ике́], *ләкин санаганда* [бер, и́кĕ, өч...]

илле ille [иле̄], *ләкин санаганда:* [...қырық, и́лĕ...]

13. Рәвешләрнең һәр төркемчәсенә караган сүзләр алфавит тәртибендә биреләләр, аваз үзгәрешләре булган очракларда чагыштыру дәрәҗәсе форманты да китерелә.

тиз tiz [тиз']

тиздән tizdən [тиздән]

сизмәстән sizməstən [сизмәстән]

14. Ярдәмлекләргә караган сүзләрнең барысы да алфавит тәртибендә үз урыннарында биреләләр. Ярдәмлекләрнең басым кабул итмичә басымлы сүзгә ияреп кенә килгән очраклары аерым күрсәтелә.

белән belən [бĕлән], *ешрак, энклитика:* бала белән [ба°лабĕлән]

бүтән II *(ярдәмл.)* bütən – *гадәттә, энклитика:* синнән бүтән [синәмбүтән]

15. Сүзлектә ымлыкларның һәм ияртемнәрнең бер, ике компонентлылары бирелә. Кирәк очракларда аларның әйтелеш үзенчәлекләре дә аңлатыла.

## *Шартлы кыскартылмалар*

*авто.* – автомобиль
*алм.*–алмашлык
*анатом.* – анатомик
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономик
*бәйл.* – бәйләгеч
*боер.* – боерык (фигыль)
*геогр.* – географик
*грам.* – грамматик
*диал.* – диалекталь (сүз)
*зоол.* – зоологик
*инф.* – инфинитив
*иск.* – искергән (сүз)
*мод.* – модаль (сүз)
*муз.* – *музыкаль*
*сөйл.* – сөйләм телендә
*сыйф.* – сыйфат
*терм.* – термин
*техн.* – техник
*туганл.* – туганлык термины
*фиг.* – фигыль
*хик.* – хикәя (фигыль)
*хим.* – химик (термин)
*ымл.* – ымлык
*энд.* – эндәш (сүз)
*ярдәмл.* – ярдәмлек

Кириллицага нигезләнгән татар әлифбасы

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Әә | Бб | Вв | Гг | Дд | Ее | Ёё |
| Жж | Җҗ | Зз | Ии | Йй | Кк | Лл | |
| Мм | Нн | Ңң | Оо | Өө | Пп | Рр | Сс |
| Тт | Уу | Үү | Фф | Хх | Һһ | Цц | Чч |
| Шш | Щщ | Ъъ | Ыы | Ьь | Ээ | Юю | Яя |

Латин графикасына нигезләнгән татар әлифбасы
(1999 нчы елда кабул ителгән вариант)

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Aa | Əə | Bb | Cc | Çç | Dd | Ee | Ff | Gg |
| Ğğ | Hh | Iı | İi | Jj | Kk | Qq | Ll | Mm |
| Nn | Ŋŋ | Oo | Ɵɵ | Pp | Rr | Ss | Şş | Tt |
| Uu | Üü | Vv | Ww | Xx | Yy | Zz | | |

# Ә д ә б и я т

Җәләй Л.Җ. Татар теленең орфоэпик нигезләре. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1953. – 72 б.

Курбатов Х.Р. Орфоэпия // Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 133-153 б.

Нуриева А.Х., Фасеев Ф.С., Мәхмүтов М.И. Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан : Тат.кит.нәшр., 1983. – 280 б.

Орфографический словарь русского языка. – М. : «Русский язык», 1985. – 464 с.

Орфоэпический словарь русского языка / Произношение, ударение, грамматические формы. – М. : «Русский язык», 1987. – 702 с.

Сафиуллина Ф.С., Ризванова Л.М. Татар теленең омонимнар сүзлеге. – Казан : «Хәтер», 1997. – 96 б.

Сәлимов Х.Х. Авыр орфограммалар сүзлекчәсе. – Алабуга : Алабуга пед.ун-ты нәшр., 2004. – 32 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. – Чаллы : «КАМАЗ» нәшр., 1995. – 128 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге турында // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1995. – Вып.2. – 104-108 б.

Татар грамматикасы. – Мәскәү : «Инсан», Казан : «Фикер», 1998.– Т. I: Фонетика, фонология, просодика, графика һәм орфография, орфоэпия, морфемика, морфонология, сүзьясалышы.– 515 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 1-3 томнар. – Казан : Тат. кит. нәшр., 1977-1981.

Фонетический разбор: Правильное произношение. – С.-Пб. : «Норинт», 2003.– 104 с.

*Приложение 1.*

## ОБ ОРФОГРАФИЧЕСКО-ОРФОЭПИЧЕСКОМ СЛОВАРЕ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Данный словарь является справочником одновременно и орфографическим, и орфоэпическим, что по сути дела является новым словом в татарской грамматической науке. Необходимость такого словаря в первую очередь связана с недостаточным уровнем развития прикладной науки о просодико-орфоэпических нормативах татарской речи. Несомненно, важна, как и для всех других языков, роль и орфографических справочников. В татарской лингвистике созданием орфографических словарей занимались в разные периоды многие исследователи. Известны, например, словари под редакцией М.З. Закиева (1983 г.), Ф.А. Ганиева (2002 г.) и др. Несмотря на чрезвычайную важность для любого языка наличия орфоэпических словарей, в татарской лингвистике этот вопрос оставался долго не изученным: первый татарский орфоэпический словарь[1] был составлен и опубликован лишь в 1995 году.

Во-вторых, важность данного словаря исходит из проблем методики преподавания родного языка, конкретно – из проблем обучения орфоэпическим нормам родного языка. «В области интонации родного языка актуальными остаются задачи повышения культуры чтения и публичной речи путем изучения богатейших возможностей интонации в передаче оттенков смысла, дифференциации просодическими средствами языковых стилей, ограничения интонации литературного языка о диалектной и просторечной интонации. Можно сказать, что перед лингвистами стоит задача создания «интонационной орфоэпии» – свода правил нормативного интонационного оформления речи»[2]. Не секрет, что в процессе обучения родному языку учителя татарского языка ставят, прежде всего, перед собой одну задачу – научить детей правильно пи-

---

[1]Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфоэпик сүзлеге. – Чаллы: «КАМАЗ» нәшр., 1995. — 128 с.

[2]Светозарова Н.Д. Интонационная система русского языка. – Л. : Изд-во ЛГУ, 1982. – С. 8.

сать, а задача обучения орфоэпическим нормам (тем более проблемы «интонационной орфоэпии») остается вне поле зрения. Для этого же необходимо, чтобы учителя татарского языка сами до тонкостей знали просодические особенности татарской речи. Таким образом, результаты данного исследования должны найти применение и в этом плане. К тому же такие педагогически ориентированные описания орфоэпических норм необходимы и для тех, кто занимается преподаванием татарского языка лицам, не знающим татарский язык, что, в свою очередь тоже представляет большую актуальность.

В-третьих, особенности орфоэпии издавна привлекали внимание специалистов в области выразительного чтения, сценической речи. Поэтому результаты нашего исследования, на наш взгляд, будут теоретической основой для работ по выразительному чтению и по сценической речи. Данные об орфоэпических нормах татарского языка могут явиться важнейшим материалом для работников радио и телевидения, в первую очередь, для дикторов и журналистов (в настоящее время в периодической печати публикуются совершенно обоснованные претензии радиослушателей и телезрителей относительно неправильного и ненормированного произношения, а иногда и просто неверного говорения на татарском языке).

В-четвертых, татарский язык, как известно, функционирует в нескольких вариантах диалектов и говоров, наибольшие различия которых от литературного татарского языка проявляются как раз на фонетическом уровне. Общие орфоэпико-просодические нормы, научно разработанные и утвержденные, должны стать фактором, объединяющим татар, проживающих в различных регионах нашей страны; фактором, делающим их речь более близкой и понятной друг другу.

Таким образом, разработка орфоэпических норм татарского языка является проблемой, важной и актуальной во всех областях и сферах: в теоретико-прикладном языкознании, в образовании и

просвещении, в культуре и даже в общественно-политической деятельности носителей языка.

Настоящая татарская графика, принятая в 1938-39 гг, основанная на кириллице, не очень соответствует звуковому строю татарского языка. Принято считать, что татарская орфография основана, главным образом, на фонетическом принципе, т, е. слова пишутся так, как произносятся, но в татарском языке имеется огромное количество слов, произношение которых сильно отличается от их написания. Это, в свою очередь, создает большие трудности при изучении татарского языка, особенно нетатарами. К тому же некоторые звуки татарского языка вообще не имеют буквенных обозначений или обозначаются буквами, которые приняты для обозначения и других звуков, т.е. многие буквы полифункциональны. И поэтому часто бывает трудно определить, какую функцию выполняет буква, т. е. какой звук она обозначает. Одна из задач словаря – помочь и в таких случаях.

Составитель данного словаря не поставил перед собой цели показать все словарное богатство татарского языка; здесь включены только около 10000 лексем, произношение которых совпадает с написанием не полностью, и возникают трудности как при произношении, так и при правописании этих слов. Трудность и объем оформления (слова даны практически на основе трех графических систем) не позволяют увеличить количество представленных слов.

Как известно, в 1999 году был принят Закон РТ «О восстановлении татарского алфавита на основе латинской графики». Несмотря на проблематичность как введения, так и реализации его, этот закон еще никем не отменен. Учитывая актуальность вопроса (надеемся в будущем – и практическую важность) о латинской графике, рядом с написанием слова на традиционной кириллице, в словаре приведены орфограммы на

этой новопринятой латинской графике. Эти орфограммы наглядно показывают, насколько близки они к произношению.

В словарь вошли общеупотребительные слова татарского языка и арабо-персидские заимствования. Русские заимствования же и слова, вошедшие в татарский язык через русский язык, которые произносятся в татарском языке по орфоэпическим нормам русского языка, в словарь не были включены, поскольку правила произношения таких слов можно найти в любом орфоэпическом словаре русского языка. В словарь вошли лишь омографы, т. е. слова, которые одинаково пишутся, а произносятся по-разному, типа «бал» – [ба$^{о}$л] «мед» и [бал] «праздник» (омонимы во всех случаях отмечены римскими цифрами).

Словарь основан на основных орфоэпических правилах татарского языка. Эти правила связаны с законами сингармонизма, с закономерностями позиционных и комбинаторных звуковых изменений.

Как известно, литературное произношение делится на два вида: полный стиль и разговорный стиль. Полный стиль применяется в случаях, когда требуется особо четкое произношение (речь дикторов, артистов, учителей), а разговорный – в обычном разговорном общении. В разговорной речи более ясно отражаются звуковые изменения, выпадение звуков. В словаре иногда приводятся оба варианта произношения: сначала – вариант полного стиля, затем – разговорного стиля: [бөгө̆лү́$^{w}$], *яки* [бө̆глү́$^{w}$].

При определении места ударения учитывались закономерности словесного ударения татарского языка (см. Приложение 3). В некоторых случаях было указано и второстепенное (побочное) ударение.

В случаях вариативности ударения (см. Приложение 3) в словаре приводятся оба варианта: [филдә́й] *яки* [фи́лдәй] «как слон».

Глаголы были даны в форме имени действия, так как произношение именно этой формы отличается рядом специфических черт.

Не было возможности (и необходимости) давать полные парадигмы склонений всех слов. Они давались лишь при появлении исключений из общих закономерностей, в частности, при спряжении отдельных форм глагола.

Произношение слов в упрощенной практической транскрипции, знаки которой представлены ниже.

В словаре применены следующие знаки практической транскрипции:

[а°] – гласный [а] татарского языка, который встречается на начальном слоге и рядом с губными согласными;

[ы̆], [ŏ], [ĕ], [ө̆] – татарские гласные [ы], [о], [е], [ө], которые редуцировались в безударном слоге т. е. произносимые очень кратко;

[ō], [ы̄], [ē] – русские гласные, которые встречаются лишь в заимствованиях;

[у$^w$], [ү$^w$] – татарские гласные [у], [ү], которые находятся в абсолютном конце слова и произносятся с конечным согласным элементом [w];

[и$^й$] – гласный [и], который находится в абсолютном конце слова и произносится с конечным согласным элементом [й];

[қ], [ғ] – увулярные согласные татарского языка;

[w] – губно-губной сонант;

[’] – гортанный согласный "гамза";

[¯] – знак долготы звука, означает и удвоенные согласные, например *атта* [а°т̄а́] «на коне»;

[˘] – знак краткости звука;

[ ́ ] – знак ударения;

[ ̀ ] – знак побочного ударения

Для освоения орфоэпических норм, в первую очередь, необходимо познакомиться со звуками татарского языка и с системой ударения этого языка.

*Приложение 2.*

## ЗВУКИ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

### Гласные:

[а] – широкий гласный, в отличие от русского среднерядного [а], произносится в заднем ряду, т. е. гораздо глубже. В начальных слогах и в соседстве с губными согласными произносится с губным оттенком, огубляется ([бa°лá]);

[ә] – мягкая пара гласного [а], произносится примерно как русский [а] между двумя мягкими согласными ("мяч" [м'ач']);

[ү] – мягкая пара гласного [у], произносится примерно как русский [у] между двумя мягкими согласными ("тюль" [т'ул']);

[о] – гласный заднего ряда, полуузкий, в отличие от русского [ó], произносится очень кратко, особенно в безударном слоге;

[ө] – мягкая пара гласного [о], произносится примерно как русский [о] между двумя мягкими согласными ([л'óн'а] "Лёня"), только очень кратко;

[ы] – гласный заднего ряда, полуузкий. В отличие от русского среднерядного, узкого [ы̄], произносится еще и очень кратко;

[е] – мягкая пара гласного [ы], отличается от русского [ē] лишь очень кратким произношением;

[у] и [и] – произносятся точно так же, как и русские [у] и [и].

### Согласные:

[в], [ц], [щ] – употребляются лишь в русских заимствованиях;

[б], [п], [д], [т], [г], [к], [ж], [ш], [ф], [з], [с], [й], [м], [н], [л], [р] – произносятся почти точно так же, как и аналогичные руские согласные.

[w] – отличается от русского губно-зубного, шумного [в] тем, что это губно-губной сонант. При произношении этого

согласного губы собираются вместе, образуя трубочку, через которую проходит воздух;

[ҡ], [ғ], [х] – увулярные согласные, в отличие от русских и татарских [к], [г] и от русского [х], которые образуются поднятием задней части языка по направлению к мягкому небу, при артикуляции [ҡ], [ғ], [х] увула (язычок) опускается по направлению к задней части языка;

[ң] – увулярный носовой сонант, образуется путем опускания язычка и мягкого неба, а его мягкий вариант [ң’], встречающийся в соседстве с переднерядными гласными, образуется поднятием задней части языка и опусканием мягкого неба, что открывает проход в носовую полость. Эти звуки несколько напоминают звукосочетания [нғ] и [нг];

[ч] – щелевой согласный, в отличие от русской аффрикаты [$^{т}$ч], этот звук произносится без элемента [т]. Звучание этого звука очень похоже на сильно палатализованный (очень мягкий) [ш’];

[җ] – звонкая пара [ч], произносится как очень мягкий [ж], ("вожжи", [во̄ж’и]);

[h] – фарингальный звук, образуется выдыханием воздуха через небольшое сужение в глотке. Это – звук дыхания (например, произносится, когда человек глубоко вздохнул);

[’] – "гамза", при артикуляции этого звука голосовые связки смыкаются, а затем внезапно размыкаются (как при легком кашле).

При произношении согласных надо учесть одно: в татарском языке нет самостоятельных твердых и мягких согласных (как в русском языке), поэтому рядом с мягкими (переднерядными) гласными произносится мягкий вариант согласного, а рядом с твердыми (заднерядными) гласными – твердый вариант.

*Приложение 3.*

## ОБ УДАРЕНИИ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

Татарский язык также относится к языкам со связанным ударением — словесное ударение в нем очень часто падает на последний слог. В то же время это ударение подвижное — при присоединении аффиксов к словам ударение передвигается дальше к концу слова: *бала́ – балала́р – балаларда́ – балалардагы́* и т.п.

Слова, заимствованные в более раннюю пору, приспособляясь к законам татарского языка, изменяли и свое ударение: *бо́чка – мичкә́, дёготь – деге́т, моча́ло – мунчала́* и т.п.

Более поздние заимствования сохраняют ударение оригинала, и если у них ударение не на конце слова, то при прибавлении аффиксов оно остается на своем месте (*а́втор –а́вторлар – а́вторларга),* а если эти слова с ударением на конце слова, то при аффиксации они переносят свое ударение на последний аффикс (*сове́т – советла́р – советларга́).*

Некоторые аффиксы татарского языка не могут быть ударенными. Такие аффиксы не принимают и обычно не «пропускают» ударение дальше себя.

Это следующие аффиксы:

а) аффиксы категории лица в спрягаемых формах глагола (кроме III лица): *алга́нмын* ‘я взял’, *алга́нсың* ‘ты взял’, *алы́рмын* ‘я возьму’, *алы́рбыз* ‘мы возьмем’ и т.п.;

б) аффиксы сказуемости (кроме III лица): *укучы́мын* ‘я ученик’, *көчле́сең* ‘ты силен’;

в) аффиксы отрицания *-ма/-мә, -мый/-ми: а́лма* ‘не бери’, *а́лмагыз* ‘не берите’, *а́лмый* ‘не берет’;

г) аффиксы (частицы) вопроса *-мы/-ме: алдыла́рмы* ‘взяли ли’, *бара́мы* ‘пойдет ли’ и т.п.;

д) деепричастные аффиксы *-ганчы/-гәнче, -канчы/кәнче: а́лганчы* ‘пока не взял’, *ки́ткәнче* ‘пока не ушел’ и т.п.;

е) словообразующий аффикс наречия *-ча/-чә: тата́рча* ‘по-татарски’, *сине́ңчә* ‘по-твоему’ и т.п.

Некоторые слова татарского языка имеют связанное ударение на первом слоге:

а) формы II лица повелительного наклонения: *а́тла* ‘шагай’, *э́шләгез* ‘работайте’, *у́тырыгыз* ‘садитесь’ и т.п.;

б) вопросительные, определительные, отрицательные местоимения: *ка́йсы* ‘который’, *нә́рсә* ‘что’, *ни́гә* ‘почему’, *ба́рлык* ‘весь’, *һә́рбер* ‘каждый’, *һә́ммә* ‘все’, *бе́рнәрсә* ‘ничто’, *бе́ркайчан* ‘никогда’, *шу́ндый, мо́ндый* ‘такой’ и т.п.;

в) большинство союзов: *лә́кин, ә́мма* ‘но’, *ба́ры, фә́кать* ‘лишь’, *чө́нки* ‘потому’, *гә́рчә* ‘хотя’, *я́гъни* ‘значит’ и т.п.;

г) некоторые наречия: *ба́йтак* ‘довольно много’, *гая́ть* ‘очень’, *тә́мам* ‘окончательно’, *кө́чкә* ‘насилу’, *һа́ман* ‘все еще’, *хә́зер* ‘сейчас’ и т.п.

Надо отметить то, что большинство слов, входящих в последние две группы, является заимствованиями из арабского и персидского языков, и есть основание полагать, что они сохраняют ударение языка-оригинала.

Некоторые слова в татарском языке не имеют ударения и вместе со словом, несущим на себе ударение, составляют фонетическое слово (фонетическое слово, как известно, – это либо одна словоформа, несущая на себе ударение, либо сочетание в потоке речи ударной словоформы с соседней безударной словоформой).

Если входящая в состав фонетического слова безударная словоформа находится перед ударной словоформой, то первая называется проклитикой, если она находится после ударной словоформой, то безударная словоформа называется энклитикой.

В качестве проклитик выступают:

а) некоторые разделительные и подчинительные союзы: *я, яисә, яки, әгәр, гуя, ягъни: я‿си́н, я‿ми́н,* ‘или ты, или я’, *әгәр‿килсә́* ‘если придет’ т. п.;

б) некоторые частицы типа *фә́кать, тик, ни, әллә: тик‿си́н,* ‘только ты’, *ни‿алга́, ни‿артка́* ‘ни вперед, ни назад’, *әллә‿ба́р, әллә‿ю́к* ‘есть ли, нет ли’ и т.п.

В качестве энклитик выступают:

а) некоторые союзы (*ки, да/дә, та/тә, ни...ни): шундый яхшы́‿ки...* ‘такой хороший...’ *килде́м‿дә...* ‘пришел и...’, *алды́‿ни, а́лмады‿ни* ‘хоть взял, хоть нет’ и т.п.;

б) некоторые частицы (*бит, ич, ләбаса, да/да, та/тә, ук/үк): тапты́м‿бит* ‘нашел таки’, *ба́р‿ич* ‘есть же’, *шу́л‿ук* ‘тот же’, *күрде́м‿лә* ‘видел же’, *ю́к‿ләбаса,* ‘нет же’;

в) некоторые модальные слова (*икән, кирәк, тиеш, соң): бара́‿икән > бара́йкән* ‘идет, оказывается’, *шу́л‿кирәк* ‘та́к и надо’, *табарга́‿тиеш* ‘должен найти’ и т.п.;

г) некоторые вспомогательные глаголы: *килә́‿иде* ‘приходил’, *эшли́‿тор* ‘пока работай’, *кү́рмәгән‿бул* ‘притворяйся, что не видишь’ и т.п.;

д) в некоторых случаях энклитиками могут стать и словоформы знаменательных слов. Экспрессивные частицы *ап-, оп-, ямь-, зәп-, кап-, кып-, көпә-, нәп-, неп-, сап-, туп-, түм-, чуп-, дөм-, чалт, шыр, җете, утә, иң* и др., предшествующие прилагательным и наречиям, иногда принимают на себя ударение, и тогда следующая за ними словоформа оказывается безударной: *а́п-ак* ‘совершенно белый’, *кы́п-кызыл* ‘очень красный’, *көпә́-көндез* ‘средь белого дня’, *шы́р ялангач* ‘совершенно голый’, *и́ң шәп* ‘самый хороший’ и т.п.

Особый интерес представляет в этом отношении постпозитивная частица *гына/генә/кына/кенә.* Употребляясь при глаголах, наречиях и прилагательных, эта частица придает им ограничительный оттенок и, теряя ударение, становится энклитикой: *ба́р‿гына* ‘толко иди’, *ти́з‿генә* ‘по быстрому’, *я́шь‿кенә* ‘моложавый’ и т.п. А при существительных, местоимениях, числительных эта частица служит для их логического выделения и, принимая ударение, превращает предшествующие словоформы в проклитики: *ат‿кына́* ‘всего лишь конь’, *шул‿гына́* ‘только тот’, *бер‿генә́* ‘лишь раз’ и т.п.

Многосложные проклитики и энклитики, а также многосложные парные, сложные слова иногда имеют ослабленное (побочное) ударение: *карап тора* [қаᵒра́птора̀] ‘смотрит’, *һәрвакыт-*

*тагыча* [һә́рваᵒқыта̄ғы̆ча] ‘как всегда’ и т.п.

В связи с тем что в татарском языке словесное ударение относительно слабое, встречается явление вариативности ударения (возможности различного ударения в одном и том же слове). Иногда вариативность связана с семантической или стилистической дифференциацией. Например, в словах *бугéн* ‘сегодня’, *былéл* ‘в этом году’ нормативным считается конечное ударение, а вариативное начальное ударение служит для логического выделения: [бӳгĕн] ‘именно сегодня’. Иногда могут сосуществовать варианты одного и того же слова даже при отсутствии какой-либо дифференциации между ними, например, [уқы́маска] и [уқы̆маска́] ‘не читать’. Видимо, в таких случаях целесообразно квалифицировать варианты следующим образом: один – как предпочтительный, другой – как допустимый.

*Справочное издание*

Салимов Халил Халимович

# Орфографическо-орфоэпический словарь татарского языка

*(на татарском языке)*

Форматы 60 x 84 1/16 . Офсет кәгазьдә.
Нәшер-хисап табагы 12,0. Тиражы 3000 данә.

"Яңалиф" нәшрият йорты.
420088, Казан, Ак. Губкин ур., 50.
Тел.: (8432) 72-55-73.

"Экс-Пресс-Плюс" нәшрият-полиграфия үзәгендә басылды.
Казан, Даурия ур., 20, Тел./факс: (8432) 98-64-15.